КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 сентябрь г.Казань № 724

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда түләүләр турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 25 гыйнвар, 32 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 17 октябрь, 497 нче; 2010 ел, 27 декабрь, 1121 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы, 2022 ел, 16 май, 443 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмалар ятмалары булган җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда түләүләр турындагы нигезләмәгә, 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.1. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләү файдалы казылмалар ятмаларын эзләү һәм бәяләү максатларында җир асты байлыкларыннан файдаланучыга бирелгән (җир асты байлыкларын дәүләт геологик өйрәнүен гамәлгә ашырудан тыш) файдалы казылмалар ятмаларын разведкалау өчен, углеводород чималы саклагычларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы өчен алына.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел,

29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче, 2022 ел, 5 март, 196 нчы; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 6 сентябрь, 964 нче, 2022 ел, 16 ноябрь, 1218 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1483 нче, 2023 ел, 14 апрель, 462 нче, 2023 ел, 5 август, 946 нчы, 2023 ел, 06 октябрь, 1252 нче, 2023 ел, 28 декабрь, 1712 нче, 2024 ел, 10 май, 316 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

3.3.3 пунктчаның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруларны киметү максатларында торак пунктларда, ял һәм туризм урыннарында, махсус сакланылучы табигать территорияләрендә транспорт һәм башка хәрәкәтләнү чараларының керүенә һәм хәрәкәт итүенә чикләүләр кертә;»;

3.3.6 пунктчаның унберенче абзацында «төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылучы территорияләр» сүзләрен «төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләре» сүзләренә алмаштырырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин